| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ ЧУКМАРЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ** |
| Село Чукмарлы, улица Советская дом 41, 423367 Телефон 4-90-38 | Чукмарлы авылы, Совет урамы, 41 йорт, 423367 Телефон: 4-90-38 |

ОГРН 1031604000130 ИНН/КПП 1636001241/163601001 ОКАТО 92253880000

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 сентябрь 2019 ел** **Чукмарлы авылы** **№ 16**

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Законының 20 статьясы 1 пункты, Чукмарлы авыл җирлеге Уставы, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә: "2020 елда Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча I группа инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:
- Чукмарлы авылы зиратын ремонтлау буенча эшләргә түләү;
- Нарат Асты авылы урамына вак таш җәю (таш ташу);
- Чукмарлы, Нарат-Асты авылларындагы юлларны кыш көне кардан чистарту;
- Чукмарлы, Нарат-Асты авылларында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май)

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Чукмарлы авыл җирлеге Советы рәисе: И.Х.Хадиуллин